**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 18 апрелендәге 1231 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Мәскәү районында**
**ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарга 1-2 номерлы кушымталар нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитут характеристикасы:

- йогынты ясала торган өлкә мәйданы – 22299 кв.м;
- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары – 16:50:310603:58, 16:50:310603:168, 16:50:310603:59, 16:50:310603:60;
- хокуклар чикләнә торган кадастр кварталы – 16:50:310603;
- урнашу урыны: Казан шәһәре, Мәскәү районы;
- билгеләү максаты: төзелеш материалларын һәм башка материалларны саклауга кую, газ белән тәэмин итү системасының «Казан 5 нче газ бүлү станциясеннән перспективалы Зур Яшел Үзән торак пунктына кадәр (алга таба Яңа Тура газ бүлү станциясе белән тоташтыру каралган) поселокара газүткәргеч» линия объекты төзелешен тәэмин итү өчен кирәкле капиталь булмаган биналар, корылмалар (коймаларны, көнкүреш корылмаларын, түбәле корылмаларны да кертеп) төзү һәм (яки) төзелеш техникасын урнаштыру;
- билгеләү вакыты: 3 ел;

1.2. гариза бирүче: «Газпром газификация» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 20 ноябрендәге 878 номерлы «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында»гы карары, Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округы Генераль планы, Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов һәм «Газпром» гавами акционерлык җәмгыяте идарәсе рәисе А.Б.Миллер тарафыннан 2022 елның 12 октябрендә расланган 2022-2025 елларга Татарстан Республикасын газ белән тәэмин итүне һәм газлаштыруны үстерү программасы, «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан бирелгән 2023 елның 7 апрелендәге 06-Ю/13-23-И номерлы техник шартлар,

«Газпром газификация» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан эшләнгән 5000.030.П.0/0.1589-ППО төзелешне оештыру проекты.

2. Сервитутны гамәлгә ашыру белән бәйле рәвештә җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яки сизелерлек кыенлашачак вакыт 10,2 айны тәшкил итә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут өчен түләү Россия Федерациясе Җир кодексының 39.46 статьясындагы 2, 3, 4, 5, 7 һәм 8 пунктлар нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1-2 номерлы кушымталар нигезендә чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

5. Әлеге карарны, 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.


7. «Газпром газификация» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлекләрен, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яки агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктлар белән каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлекләрендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң өч айдан да соңга калмыйча, алардан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 18 апрелендәге
1231 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең Мәскәү районында**
**ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**




Масштаб: 1:10000
Координаталар системасы: МСК-16

Шартлы билгеләр:

| | |
|---|---|
| | Сервитутлар (Статусы булмаган) |
| | Җир кишәрлекләре |
| | Кызыл линияләр (расланмаган) |
| | Капиталь төзелеш (линия) объектлары |
| 16:50:310603 | кадастр кварталы |
| 16:50:310603:58, 16:50:310603:168, 16:50:310603:59, 16:50:310603:60 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |

___________________________